ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

1 статья. **Татарстан Республикасында беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру**

«Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезендә беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган исемлек нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары карамагындагы оешмаларга тапшырыла дип билгеләргә.

2 статья. **Татарстан Республикасында беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкаруны финанс ягыннан тәэмин итү**

Беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру вәкаләтләрен әлеге Законның 1 статьясында күрсәтелгән оешмалар тарафыннан башкаруны финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 18-ТРЗ